| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**21.11.2019** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2520** |
|---|---|---|

Зеленодольск муниципаль районы
Октябрь авыл җирлеге муниципаль
берәмлегенең җирдән файдалану һәм
төзелеш корылмалары буенча
комиссия төзү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 31 нче статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче кушымта нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия төзергә
2. Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 нчы елның 21 нче ноябрендәге
2520 нче номерлы карарына карата
1нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге Муниципаль Берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия

| № т/б | Ф.И.Ат. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Дементьев Александр Петрович | Октябрь авыл җирлеге башлыгы |
| 2. | Вишневская Анастасия Александровна | ТР ЗМР Октябрь авыл җирлеге Башкарма комитетының җитәкче урынбасары |
| 3. | Артемова Анна Сергеева | ТР ЗМР Октябрь авыл җирлеге Башкарма комитетының әйдәп баручы белгече. |
| 4. | Бугарчева Илсөяр Равил кызы | ТР ЗМР Октябрь авыл җирлеге Башкарма комитетының баш хисапчысы |
| 5. | Егоров Дмитрий Валерьевич | ТР ЗМР Октябрь авыл җирлеге Советы депутаты |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 нчы елның 21 нче ноябрендәге
2520 нче номерлы карарына карата
2нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы
Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары
кагыйдәләре буенча комиссия турында
Нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалануны һәм төзелеш корылмаларын алып баруны җайга салу системасының нәтиҗәле эшләвен булдыру, эзлекле камилләштерү һәм тәэмин итү өчен Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре буенча комиссия (алга таба - Комиссия) төзелә.

Комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә төзелә.

Комиссия даими эшли торган булып тора һәм үз эшчәнлеген билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашыра.

Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

Комиссия үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр, шулай ук кызыксынган юридик һәм физик затлар белән үзара бәйләнештә алып бара.

## 2. КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

2.2. Комиссия рәисе булмаган очракта, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИЯ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1. Комиссия компетенциясенә:

3.1.1. Җирдән файдалануны һәм төзелеш корылмаларын алып баруны җайга салу системасын эзлекле рәвештә Формалаштыру һәм камилләштерү

процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләрен эшләү, ә алга таба аларны тормышка ашыру;

3.1.2. Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләрен эшләүгә бәйле рәвештә гражданнар һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

3.1.3. Ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү:

- Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш корылмалары кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында;

- Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турындагы сораулар буенча;

- Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге территориясендә рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүне кире кагуга рөхсәт бирү сораулары буенча;

- Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру проектлары буенча;

- Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен ызанлау проектлары буенча.

3.1.4. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә чыгару, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тәкъдимнәр әзерләү керә.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия кирәк булган саен, ләкин кимендә айга бер тапкыр җыела.

4.2. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия карары Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

4.4. Комиссия эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү Зеленодольск муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге Башлыгына йөкләнә.